МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2019 Казан ш. № 17-75

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

"Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" 27 декабрь, 1991ел, № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1.Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Өлкән белгеч Г.И.Гыймадиевага бу боерык белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының
18.07. 2019 №17-75
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Кагыйдәләр, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 27 декабрь, 1991ел, № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Журналистларны аккредитацияләү (алга таба – аккредитация, министрлык) тәртибен җайга сала.

1.2. Журналистларны аккредитацияләү, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре тарафыннан тапшырылган заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, һәр ел саен үткәрелә.

II. Аккредитацияләнүгә хокук

2.1. Аккредитацияләнү хокукына, милек формасына һәм гамәлгә куючылары составына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит илләрнең массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре дә хокуклы. Чит илнең массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгында аккредитацияләнүен раслау кирәк.

III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә мәгълүмат урнаштыру юлы белән, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә журналистларны аккредитацияләүне үткәрү сроклары турында алдан ук хәбәр итеп куя.

3.2. Журналистны аккредитацияләү турында мәсьәләне карап тикшерүгә нигез булып массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең рәсми бланкында рәсмиләштерелергә һәм баш мөхәррирнең имзасы һәм мөхер белән расланылырга тиешле журналист турында мәгълүматны үз эченә алган заявка тора.

3.3. Заявкада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), аның вазифасы, эш һәм кесә телефоннары номерлары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы атамасы, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә. Чит илнең масакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгында аккредитацияләнүен раслаучы документлары өстәмә кушып бирелә.

3.4. Бу Нигезләмәнең 3.1пунктында күрсәтелгән сроктан соң министрлыкка алынган заявкалар, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.2.,3.3. пунктлары иаләпләренә туры килмәүче заявкалар карап тикшерелми.

3.5. Министрлыкта журналистларны аккредитацияләү турында карарны министр, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре һәм журналистлары бу Кагыйдәләрне үтәгән очракта, кабул итә.

IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар хокуклы:

чарада булуга;

чара турында министрлык карамагындагы рәсми документлар (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмати-белешмә, статистика, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алуга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүмати-белешмә материаллары белән танышуга;

Россия Федерациясе законында билгеләнгән башка хокукларга.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чараның регламентын үтәүгә һәм аның барышына тыкшынмауга – ул массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса:

чарада катнашучыларның эшчәнлегенә комачауламауга;

язмаларда (эфирда эшләгәндә) министрлык тәкъдим иткән пресс-релизлардан, мәгълүмати-белешмә, статистика, аналитик материаллардан һәм башка материаллардан файдаланган очракта мәгълүмат чыганагын күрсәтергә;

һөнәри эшчәнлегендә министрлык эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килмәүче мәгълүматларны таратмауга.